| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2019 Казан шәһәре № 10-65/кс

«ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2020-2024 елларга эчә торган суга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

3. Шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2020-2024 елларга, салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-65/кс карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга 2020-2024 елларга кадендарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | | 2024 ел | |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр |
| | Кукмара муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 1 | «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 30,13 | 31,31 | 31,31 | 32,02 | 32,02 | 33,12 | 33,12 | 33,89 | 33,89 | 35,04 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-65/кс карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2020-20243 елларга эчә торган суга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2020 | 12 065,78 | 1 | - | 12,3 | 1,46 |
| | | 2021 | 12 387,09 | 1 | - | 12,3 | 1,46 |
| | | 2022 | 12 753,74 | 1 | - | 12,3 | 1,46 |
| | | 2023 | 13 131,26 | 1 | - | 12,3 | 1,46 |
| | | 2024 | 13 519,94 | 1 | - | 12,3 | 1,46 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге